ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.10.2024 г. Заинск № 532

**2025 елга “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирүгә муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында сәнгать -эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2025 елга расларга:

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең сәнгать -эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар;

сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга 0,75 күләмендә төзәтмә коэффициенты.

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланды
«04» 10 2024 ел № 532

**“Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә**

# НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (бер укучыга елына сумнар) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку срогы | дүрт еллык уку срогы | биш еллык уку срогы | җиде еллык уку срогы | иртә һөнәри ориентация |
| Музыка сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 78 737 | 89 952 | 115 527 |
| Музыка сәнгате | авыл җирлеге | | | 83 699 | 95 607 | 122 722 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 41 684 | | 37 010 | 88 817 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 44 232 | | 39 296 | 94 291 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 87 814 | 72 312 | 265 068 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 93 401 | 76 913 | 281 919 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 36 926 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 39 265 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 80 741 | 77 524 | 124 555 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 85 893 | 82 475 | 132 470 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 121 586 | | 116 554 | | 191 128 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 129 245 | | 123 915 | | 203 145 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 62 682 | | 58 352 | 58 267 | 87 898 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 66 606 | | 62 016 | 61 926 | 93 302 |